РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, д.38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

423950, Урыссу ш.т.б., Пушкин урамы, 38
тел.: (85593) 2-74-16, факс: (85593) 2-62-20

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 08 » 02 2021 г. № 68

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 22 октябрендәге «Ютазы муниципаль районы бюджетыннан Урыссу шәһәр тибындагы поселогыннан 11 чакрымнан артыграк ераклыктагы һәм аз халыклы торак пунктларга беренче әһәмияттәге тауарлар китерү белән бәйле, кулланучылар кооперациясе оешмалары чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү Тәртибен раслау турында» 731 номерлы Карарына өстәмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Бюджет кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Бюджет кодексы, Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, 2020 елның 28 апрелендә Татарстан Республикасы Ютазы район Советының №18 карары белән кабул ителгән «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставы, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының 2006 елның 12 гыйнварындагы 1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты турында Нигезләмә нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Башкарма комитетының 2018 елның 22 октябрендәге 731 номерлы “Ютазы муниципаль районы бюджетыннан Урыссу шәһәр тибындагы поселогыннан 11 чакрымнан артыграк ераклыктагы һәм аз халыклы торак пунктларга беренче әһәмияттәге тауарлар китерү белән бәйле, кулланучылар кооперациясе оешмалары

чыгымнарының бер өлешен каплауга субсидияләр бирү Тәртибен раслау турында” Карарына түбәндәге өстәмәләрне кертергә:

1.1. 2 пунктның 2.3 пунктчасына түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«- Субсидия алучының салымнар, җыемнар, иминият кертемнәре, пенялар, штрафлар, салымнар һәм җыемнар турында Россия Федерациясе законнары нигезендә түләнергә тиешле процентлар түләү буенча үтәлмәгән бурычлары булмау.».

2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының Бердәм Порталында Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Ютазы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комтитет җитәкчесе С.П. Самонина

Р. М. Якупов
2-74-14